ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2021 377

«Алабуга муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон, 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы «Җир асты байлыклары турында» Федераль законрың 5 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль вазыйфаларны башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов